**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_13_» ___02_____ 2026 ел.** **№ __25___**

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында»2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән иң чик күрсәткечләрен билгеләү Методикасы, «ТР бәяләүчеләр берлеге» НП Эксперт-консультация Советының «Бәяләр диапазонын билгеләү турында»гы 2026 елның 29 гыйнварындагы 12 номерлы хаты, Башкарма комитетның 2026 елның «13" февралендәге 24 номерлы "2026 елга Азнакай муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативын билгеләү турында»гы карары нигезендә, карар бирә:

1. 2026 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

Ялгыз яшәүче гражданин өчен-1 200 006 сум.;
Ике кешелек гаилә өчен-2 400 012 сум.;
Өч кешелек гаилә өчен-3 600 018 сум.;
Дүрт кешелек гаилә өчен-4 800 024 сум.;
Биш кешелек гаилә өчен-6 000 030 сум.;
Алты кешелек гаилә өчен-7 200 036 сум.;
Җиде кешелек гаилә өчен-8 400 042 сум.;
Сигез кешелек гаилә өчен-9 600 048 сум.;

Тугыз кешелек гаилә өчен-10 800 054 сум.;

Ун кешелек гаилә өчен-12 000 060 сум.

1.2. Гражданның бер гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме 44 571 сум 65 тиен тәшкил итә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына 1 нче кушымта
«_____» _________2026 № _______

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасы**

1. Муниципаль торак фондының торак урыннар бирү нормасы буенча торак урыннар сатып алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече (алга таба исәп-хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ, биредә

СЖ – исәп-хисап күрсәткече;

НП – әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзалары саны;

РЦ – әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган, Татарстан Республикасында торак урынны сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмаган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе.

Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлегенең 2026 елның 29 гыйнварындагы 12 номерлы «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» хаты нигезендә, Азнакай муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясе 66 667 сум тәшкил итә.

2. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданин милкендә булган һәм салым салынырга тиешле милек хакының максималь күләме СЖ исәп-хисап күрсәткеченә тигез итеп кабул ителә.

Гражданин гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме түбәндәгечә билгеләнә:

1) Торак урын сатып алу өчен ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә, СЖ исәпләү бәясе буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып, формула буенча билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-КП}$) / (0,25 х РС), биредә

ПД — СЖ исәпләү бәясе буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ — исәпләү күрсәткече;

ПС — айлык кредит процент ставкасы (унлы өлеш), ипотека торак кредитлау ставкасы - елга 16%, ягъни 16%/100/12=0,013 айга);

КП — кредитның бөтен срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны 292,1 ай тәшкил итә;

РС — гаилә әгъзалары саны;
0,7 — кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;
0,25 — кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте.

**Уртача айлык җыелма керемнең максималь күләмен билгеләү**

| Гаилә әгъзалары саны РС | Торак урын бирү нормасы буенча базар бәясенең исәплəү күрсәткече (СЖ) | Айлык кредит процент ставкасы (уртача еллык-16%) ПС (16/100/12) | 0,7*СЖ*ПС | 1-(1+ПС)$^{-292,1}$) | 0,25*РС | Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме: |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 1200006 | 0,013 | 10920,0546 | 0,98 | 0,25 | 44571,65 |
| 2 | 2400012 | 0,013 | 21840,1092 | 0,98 | 0,5 | 44571,65 |
| 3 | 3600018 | 0,013 | 32760,1638 | 0,98 | 0,75 | 44571,65 |
| 4 | 4800024 | 0,013 | 43680,2184 | 0,98 | 1 | 44571,65 |
| 5 | 6000030 | 0,013 | 54600,273 | 0,98 | 1,25 | 44571,65 |
| 6 | 7200036 | 0,013 | 65520,3276 | 0,98 | 1,5 | 44571,65 |
| 7 | 8400042 | 0,013 | 76440,3822 | 0,98 | 1,75 | 44571,65 |
| 8 | 9600048 | 0,013 | 87360,4368 | 0,98 | 2 | 44571,65 |
| 9 | 10800054 | 0,013 | 98280,4914 | 0,98 | 2,25 | 44571,65 |
| 10 | 12000060 | 0,013 | 109200,546 | 0,98 | 2,5 | 44571,65 |

**Милекнең базар бәясен исәпләү күрсәткечен билгеләү**

| Гаилә әгъзалары саны | Торак бирү нормасы | Гомуми мәйданы | 1 кв. м өчен уртача исәпләнгән базар бәясе | Базар бәясен исәпләү күрсәткече (СЖ) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 18 | 18 | 66 667 | 1200006 |
| 2 | 18 | 36 | 66 667 | 2400012 |
| 3 | 18 | 54 | 66 667 | 3600018 |
| 4 | 18 | 72 | 66 667 | 4800024 |
| 5 | 18 | 90 | 66 667 | 6000030 |
| 6 | 18 | 108 | 66 667 | 7200036 |
| 7 | 18 | 126 | 66 667 | 8400042 |
| 8 | 18 | 144 | 66 667 | 9600048 |
| 9 | 18 | 162 | 66 667 | 10800054 |
| 10 | 18 | 180 | 66 667 | 12000060 |